
# САУМЫ, ӘЙ, ШӘҺРИ БОЛГАР

**Рәмиль Чурагулов сүзләре** **Ризван Хәким музыка**



# САУМЫ, ӘЙ, ШӘҺРИ БОЛГАР

1. Күктә янган йолдызлардай,
Җир буйлап без сибелгәнбез.
Без тарихта эзле халык
Үлем белмәс татарлар без.
*Кушымта:* Сине зурлап җыр җырлыйбыз,
Сиңа иң-иң матур җырлар.
Саумы бабамнар нигезе
Изге җирем — шәһри Болгар.
2. Мең тарафтан килдек сиңа
Милләтемнең ак сәҗдәсе
Саумы изге Болгар җире
Татарымның мәдинәсе
3. Тарих саклый һәрбер ташың
Изге җиркәем Болгарым.
Татарымның үткәне бар,
Киләчәге дә бар аның.
*Кушымта:* шул ук.
4. Ерак бабамнан мираска
Калган телем, иманым бар.
Бездә горур татар каны
Тукай, Җәлилләр каны бар.
*Кушымта:* шул ук.